| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**СОВЕТ**<br>**СТАРОМЕНЗЕЛЯБАШСКОГО**<br>**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**<br>**САРМАНОВСКОГО**<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**САРМАН**<br>**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**<br>**ИСКЕ МИНЗӘЛӘБАШ**<br>**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24.11.2019 г. № 12

"Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022- 2023 елларга план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында"

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022- 2023 елларга план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» мәгълүмат тыңлап фикер алышканнан соң, Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022- 2023 елларга план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» мәгълүматны игътибарга алырга (1нче кушымта).
2. Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022-2023 елларның планлы чорына социаль-икътисадый үсеш фаразын үтәүне тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башлыгы А.Н.Габдрахманов

Приложение 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022- 2023 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | хисап | хисап | бәяләмә | фараз | фараз | фараз |
| Халык саны | кеше | 925 | 897 | 910 | 920 | 920 | 920 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 0,76 | 0,97 | 0,45 | 0,1 | 1 | 1 |
| Мөгезле эре терлекләр саны | баш | 311 | 310 | 320 | 325 | 325 | 325 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 0,98 | 0,97 | 1,03 | 1,02 | 1 | 1 |
| Инвестицияләр | мең сум | 1000 | - | - | 1000 | 1000 | 1000 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 1000 | - | - | 1 | 1 | 1 |
| Торак тапшыру | кв.м. | 464 | 255 | 200 | 200 | 200 | 200 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 4,64 | 0,55 | 0,78 | 1 | 1 | 1 |
| Хезмәткә түләү фонды | мең сум | 155 652,5 | 157 657,8 | 149 774,9 | 146 779,4 | 155 439,4 | 155 750,3 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 1,04 | 0,96 | 0,97 | 1,01 | 1,01 | 1,01 |
| Уртача айлык хезмәт хакы | сум | 28 953,2 | 44 385,6 | 41 328,6 | 40 502,0 | 40 479,0 | 43 264,0 |
| Хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны | кеше | 448 | 296 | 302 | 302 | 320 | 300 |
| Эшкуарлар саны (КФХ,ШЭ) | кеше | 12 | 11 | 12 | 13 | 13 | 13 |
| Эшсезләр саны | кеше | 2 | - | 7 | 5 | 4 | 3 |

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге хисапчысы Сафина Сафина Г.И.

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022- 2023 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразына аңлатма язуы

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш фаразына керем чыганакларын һәм бюджет чыгымнарының статьяларын формалаштыру өчен кирәк булган төп макроикътисади күрсәткечләрне үз эченә ала.

2021-2023 елларга Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш фаразы Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән 2021-2023 елларга Россия Федерациясе икътисады эшчәнлегенең сценар шартларының база варианты нигезендә эшләнде, Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең 2020 елның көтелә торган нәтиҗәләрен һәм 2021-2023 елларда икътисад һәм социаль өлкә үсеше тенденцияләрен бәяләүне исәпкә алып, 2021-2023 елларга Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән инфляция һәм индекс-дефляторлар күрсәткечләрен кулланып эшләнде.

2021-2023 елларда «Urals» нефтенә бәяләрнең баррель өчен 43,3-46,5 АКШ доллары дәрәҗәсендә уртача динамикасы фаразлана.

2021 елда долларның уртача еллык курсы АКШ доллары өчен 70,8 сум, 2022 елда АКШ доллары өчен 71,1 сум булыр дип фаразлана. 2023 елда, Россия Икътисадый үсеш министрлыгы фаразына караганда, доллар курсы АКШ доллары өчен 72,4 сум тәшкил итәчәк.

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге составына Иске Минзәләбаш, Кужак авыллары керә.

2021 елга Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегендә халык саны 920 кеше, 2022 елга – 920 кеше, 2023 елга – 920 кеше тәшкил итәчәк.

Авыл хуҗалыгын үстерү фаразы «Җәлил» агрофирмасы ЖЧҖенең булган потенциалын һәм килеп туган үсеш тенденцияләрен, фермер һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны, шулай ук «Агросәнәгать комплексын үстерү» һәм «Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» программаларын гамәлгә ашыру буенча билгеләнгән чараларны исәпкә алып эшләнгән.

Хәзерге вакытта авыл җирлеге территориясендә «Җәлил» агрофирмасы ЖЧҖ, «Земля плюс» ЖЧҖ һәм КФХ Әшрәфуллин И. Р. ,КФХ Сәлимгәрәев Ф. Ф., КФХ Закиров И. И., КФХ Гарифуллин З. С., КФХ Габдрахманов Р. М., КФХ Габдрахманова Ф. Ф. эшчәнлек алып баралар.

2020 елда авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләме 917 804 мең сумнан артык тәшкил итәчәк. 2021 ел фаразына караганда, продукция күләме 935 233 мең сум тәшкил итәчәк, 2022 елда – 5% ка артачак һәм 982 000 мең сум тәшкил итәчәк, 2023 елда – 5% ка артачак һәм 1 030 000 мең сум тәшкил итәчәк.

2020 елда төп капиталга инвестицияләр булмады. 2021 елда грантлар хисабына 1 млн.сум күләмендә фаразлана, 2022-2023 елда үсеш темпы 0.2-1% тәшкил итәчәк һәм 1 млн. сум һәм 1 млн. сум тәшкил итәчәк.

2021-2023 елларда якынча 400 квадрат метр торак файдалануга тапшыру планлаштырыла.

2020 елда хезмәт хакы фонды 149 774,9 мең сум тәшкил итәчәк.

2021 елга хезмәт хакы фондының фаразланган күрсәткече – 146 779,7 мең сум, 2022 елда – 155 439,4 мең сум, 2023елда-155 750,3 мең сум тәшкил итәчәк.

Хезмәткәрләр саны уртача 302 кеше тәшкил итә.

2019 елда уртача айлык хезмәт хакы 27 862,6 сум тәшкил итәчәк. 2020 елга фараз буенча ул-27 031,2 сум, 2021 елда-27 410,5 сум, 2022 елда 27 874,7 сум тәшкил итәчәк.

2021 елга эшмәкәрләр саны (КФХ) 13 кеше тәшкил итәчәк, 2022 елга-13, 2023 елга-13 кеше.